БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«__15__» ____10____2019 г. № 325

**2019-2025 елларга Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында гражданнарны авария хәлендәге торак фондынан күчерү турында адреслы муниципаль программаны раслау турында**

2007 елның 21 нче июлендәге 185-ФЗ номерлы «Торак-коммуналь хуҗалыкны үзгәртеп коруга ярдәм итү фонды турында» Федераль законны тормышка ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 29 нчы марттагы 242 нче номерлы «2019-2025 нче елларга гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү буенча республика адреслы программасын раслау турында» карары нигезендә, Татарстан Республикасының Балтач район башкарма комитеты **карар бирә**:

1. 2019-2025 елларга Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында гражданнарны авария хәлендәге торак фондынан күчерү турында адреслы муниципаль программасын расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач районы Башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлегенә йөкләргә.

Җитәкче А. Ф. Хәйретдинов